**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# КАРАР
**сигезенче утырыш**

**4 май 2026 ел** **№ 31** **Теләче ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы**
**Теләче авыл җирлеге территориясендә**
**махсус мәгълүмат стендларын урнаштыру**
**урыннарын раслау турында**

«Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларын урнаштыруның түбәндәге урыннарын расларга:

1) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы, Белов ур., 5 йорт (Теләче муниципаль районының «Район мәдәният йорты» бинасы);

2) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Ачы авылы, Ленин урамы, 31 йорт (Ачы авыл мәдәният йорты бинасы);

3) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Комаровка ав., Гагарин ур., 1 й.;

4) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Екатериновка ав., Совет ур., 15 йорт.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән махсус мәгълүмат стендлары үзләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат белән чикләнмәгән затлар даирәсе тарафыннан тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген, шулай ук мондый мәгълүматны тышкы йогынтылардан яклауны тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы А.Г. Фатхуллин